# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Рус Макылы торак пунктының Заречная урамында 2026 елда гражданнар арасында үзара салым кертү турында

2025 елның 10 декабре №02

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пунктының Заречная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизацияләнгән гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан һәм күп балалы гаиләләрдән тыш, 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы П.Е.Карпухин